## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

## КАРАР №23

III чакырылыш XXXII утырышы      Урыссу ш.т.б.      2020 елның 26 мае

***2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында***

Социаль-икътисадый бурычларны комплекслы хәл итү, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, Ютазы муниципаль районының җитештерү һәм инвестицион потенциалын үстерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2014 елның 28 июнендәге «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 172-ФЗ санлы Федераль закон, 2015 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 12-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Ютазы муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы

**К А Р А Р   И Т Т Е:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына социаль-икътисадый үсеш стратегиясен расларга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты стратегик планлаштыру документларын, максатчан программаларны, эшчәнлекнең нәтиҗәләре һәм төп юнәлешләре турында докладларны, стратегия нигезендә Ютазы муниципаль районының үсеш фаразларын эшләүне тормышка ашырырга.
3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә стратегиядә каралган юнәлешләрне тормышка ашыручы программалар чараларын гомуми координацияләүне һәм җыелма планлаштыруны йөкләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

5. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. (http:pravo.tatarstan.ru).

**Ютазы муниципаль районы Башлыгы урынбсары** **З.М. Аглиева**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
ЮТАЗИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН